**Г. Тукай – тәнкыйтьче.**

**Таһир Гыйлаҗев – КФУ доценты**

Татар әдәбиятын яңа сыйфатлар белән баетып, аның үсеш юнәлешен билгеләүчеләрнең берсе булган классик шагыйрь Г. Тукай әдәби тәнкыйтьне формалаштыруга да үзеннән мәгълүм өлеш кертә. Каләме шактый шомарып, сүзләренең тасвир көче арта төшкән 1906 елларда публицистик һәм тәнкыйди мәкаләләр яза башлап, шагыйрь тиз арада тугры сүзле, принципиаль, усал тәнкыйтьче буларак танылa. Татар әдәби тәнкыйте үткән юлны гыйльми күзаллауга зур урын бирелгән "Татарская литература и публицистика начала XX века" (1966) дигән хезмәтендә М. Гайнуллин болай дип яза: "Хезмәтләрендә татар әдәбияты һәм публицистикасы тарихында беренчеләрдән буларак тәнкыйтьнең төп принциплары әйтелгән халык шагыйре Г. Тукай хаклы рәвештә татар реалистик тәнкыйтенә нигез салучы булып санала" [1.128б.] .

XX-XXI гасыр чикләрендә татар әдәбият белеме фәне яңарыш кичерә. Шушы уңайдан татар әдәбияты тарихын, теориясен һәм әдәби тәнкыйтен калыплаштыруда һәм үстерүдә зур роль уйнаган күпкатлам татар әдипләренең, галимнәренең, тәнкыйтьчеләрнең гыйльми-нәзари, әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге яңадан барланып, бүгенге көн күзлегеннән яктыртылды. Г. Тукайның тәнкыйди мирасы, кызганычка каршы, бу хәрәкәттән читтә кала. Үзгәртеп коруларга кадәр дөнья күргән М. Гайнуллин [1], М. Мәһдиев [6], Р. Мөхәммәдиев [7], И. Нуруллин [9] һ.б. галимнәрнең фәнни тикшеренүләрендә күзәтелгән берьяклы мавыгуларны, идеологик максатлардан чыгып калкулатылган аерым күренешләргә бирелгән бәяне дөреслисе бар. Г. Тукайның тәнкыйди һәм публицистик мирасында алар күрсәткән сыйфатларны нәзари яктан тирәнәйтү, тәнкыйтьченең бу өлкәдәге фәнни-теоретик үзләнүләрен төгәлләштерү, яңарту кирәклеге соралып тора.

Чыннан да, шагыйрь татар әдәби тәнкыйтен калыплаштыру һәм аны үстерүне үзенең бурычы дип саный. Әдәби барышка йогынты ясауда әдәби тәнкыйтьнең иң куәтле чара икәнлеген тирән аңлаган Тукай Җаектан Казанга кайткач ук, "Тәнкыйть кирәкле шәйдер" (1907) дигән программ характердагы мәкаләсе белән чыгыш ясый. Әлеге язмасы шагыйрьнең татар зыялыларына, укымышлыларына, әдипләренә һәм журналистларына мөрәҗәгать буларак яңгырый.

Мәгълүм булганча, Беренче рус инкыйлабының шифалы җилләре тәэсирендә татарларда матбагалар челтәре киңәеп китеп, күпләп китаплар, журналлар басыла башлый. Менә шушы шартларда Тукай матур әдәбиятка укучыларда югары әхлак кыйммәтләре, әдәби зәвекъ формалаштыру ноктасыннан якын килеп, әдәби тәнкыйтьнең кирәклеген ассызыклап чыга: "Тәнкыйть, безнең заманыбыз кебек, китаплар, брошюралар, газеталар, журналлар таулар кадәр өелеп барган бер заманда кирәкле генә түгел, ансыз торып булмый торган бернәрсә. Һәр көн арабызда төрле – төрле яңа исемнәрдә китаплар таралып тора. Һәрнәрсәнең дә үсеше чамадан артып китсә, табигый, зарарлы була. Шуңа күрә безнең дә үз тәнкыйтебез

цензорыннан үтмичә, “тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка” дигән мәкальдәгечә, халык арасына һаман таралып торган әсәрләребез арасында хөрмәтле гади укучыларыбыз өчен зарарлылары да булуы ихтимал” [12. 243 б.]. Мәкалә авторы алга таба тәнкыйтьнең фәнни нигезе мәсьәләләреннән аның алшартлары, тәнкыйтьче куелган таләпләр турында сөйләшүгә күчә. Тукай, субъективлыкны, шәхсилекне әдәби тәнкыйтьнең үзенчәлегеннән килеп чыга торган котылгысыз халәт икәнен аңлаган хәлдә, объективлыкны, әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын “зарифанә (матур) вә битарафанә (объективлык белән) тәнкыйть итү”не беренче шарт төсендә билгели. Автор тарафыннан тәнкыйтьчегә куелган таләпләрнең үзәген профессиональ әдәп, әхлакый позиция мәсьәләсе тәшкил итә. Намуслылык, таләпчәнлек, принципиальлек, тәҗрибәлелек, җаваплылык шушы үзәк тирәсендә җыелып бирелә: “Ләкин тәнкыйть итүченең дә кем очрады – шул булуы тагы ярамый. Тәнкыйтьче булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле һәм әхлаклы кеше булуы таләп ителә. Югыйсә үз файдасын күзәтеп тәнкыйть итүчеләр дә күп” [12. 245 б.]. Күренә ки, Г. Тукай, беренчеләрдән буларак, матбугат битләрендә әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе, теоретик мәсьәләләре турында сөйләшүне башлап җибәрә.

Г. Тукай бу төр иҗатында, әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләрен хәл итүгә алынудан тыш, әдәби хәрәкәтне, әдәбият мәйданында барлыкка килгән әдәби әсәрләрне бәяләүгә дә зур игътибар бирә. Шунысын әйтергә кирәк: шагыйрьнең заман әдәбияты хакындагы тәнкыйди фикерләре бу уңайдан дөнья күргән махсус язмаларда гына түгел, ә аның публицистик характердагы мәкаләләрендә дә, әдәби әсәрләрендә дә күзәтелә. Тәнкыйтьче замандашлары иҗатын яңарыш – үсеш юлына баскан милли чынбарлык, әдәби – мәдәни мохит белән тыгыз бәйләнештә карый. Үз тәнкыйди эшчәнлегендә мәдәни – тарихи мәктәпнең кагыйдәләренә таянган Г. Тукай әдәби сүзнең җәмгыятькә, халык, кеше психологиясенә тәэсир итү көченә тирән ышана. Татар әдәбиятының классик драматургы Г. Камалның 10 еллык әдәби- мәдәни эшчәнлегенә багышлап үткәрелгән чаралар уңаеннан язылган “Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсы (1910) мәкаләсендә тәнкыйтьче матур әдәбиятка җәмгыять тормышы, милли чынбарлык чагылу идеясе ноктасыннан якын килеп, әдип иҗатын югары бәяли: “Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре (“Бәхетсез егет”, “Бүләк өчен” –(Г.Т.) чын татар тормышын бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән “Бүләк өчен”дәге, угылын өйләндерә торган татар хатының рухи халәтен белү, аның өйләнү кебек олуг бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне әлхәм укыган кебек яңлыштырмый, гармонично санату фәкать, фәкат Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә хас бер эш булганга ... бу әсәрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассыйс (оста, белгеч) булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты” [10. 178 б.].

Мәгълүм булганча, Г. Тукай үзе язмаларының күбесен реалист әдип М. Гафури шигъриятен һәм прозасын бәяләүгә багышлый. Аның төрле жанрда,

төрле стильдә язылган “Милләткә файда урынына зарар” (1910) “Өч баш” (1911), “Акыллы башлар” (1910) һ.б. язмаларында шагыйрь иҗаты хакындагы аерым бәя – хөкемнәре бәхәс тудырса да, “Яңа әсәрләр (“Хәмитнең хәяты”)” (1911) рецензиясендә М. Гафуринең повесте мәктәп – мәдрәсәләрдәге татар шәкертләре тормышын, артталыкны тулы һәм дөрес күрсәтү ягыннан уңай бәяләнә: “Мәҗит Гафуриның бу әсәре, аның “Яшь гомерем”дәге “Электрик фонарена” һәм мәзкүр (искә алынган) китап әүвәлегендәге бәгъзе гүзәл тасвиратны истисна иткәндә (аерып алу), ул язган әсәрнең иң яхшысы вә иң тормыштан алынып язылганыдыр дисәк, җаиздер (дөрестер). Бу әсәрдәге бәян ителгән хәлләр, тасвирларының бер кыйсьме (өлеше) мөхәрирнең үз тормыш вә әхвәленә гаид (хәлләренә карый торган) күренсә дә, билгомум (гомумән) бөтенебез, чапкыр тормыш артыннан җитмәгән вә ничектер куарга да керешә алмаган шәкертләрнең хәл – әхваленнән гыйбарәттер” [11. 106 б.]. Бу әсәрдә үткәрелгән идеяләр искелеккә көрәш алып барган Тукайның үз әдәби – эстетик карашларына туры килә. Тәнкыйтьче әдәбиятның “сәнгатьнең билгеле бер мәсләккә хезмәт итү өчен” вазыйфасын калкытып куеп, әдәбиятка, милли чынбарлыктагы актуаль мәсьәләләрне күтәреп, аларны чишәргә, җәмгыять алга таба хәрәкәт итәргә, мәдәни алгарышка чакыручы көч итеп карый.

Г. Тукайның тәнкыйди мирасы жанр байлыгы һәм төрлелеге белән XX гасыр башы тәнкыйтендә аерылып тора. Гәрчә әдип бу юнәлештә гыйльми – нәзари эзләнүләр алып барып, теоретик характердагы язмалар белән чыгыш ясамаса да, әдәби тәнкыйтьнең жанр системасын формалаштыруга һәм аның тулы һәм бөтен бер системага әверелүенә, аны киңәйтүгә үзеннән мәгълүм өлеш кертә. Тукай яңа әдәбиятны бәяләү өчен, саф тәнкыйть жанрларын файдалану белән генә чикләнмичә, башка иҗат төрләренең жанрларына мөрәҗәгать итә, аларны иҗади файдалана, кызыклы экспериментлар ясый, жанр мөмкинлекләрен арттыра.

Г. Тукай киң файдаланган жанрлар арасында бүгенге көндә әдәбият галимнәре аерып чыгарган информатив, аналитик, әдәби-публицистик төрләрне дә күрергә мөмкин. Тукайның иҗтимагый – әхлакый позициясе әдәби – эстетик һәм фәлсәфи карашлары, эстетик зәвегы һәм идеалы әдәби барышны бәяләвендә, стилендә, бәяләү формаларында хәлиткеч роль уйный. Күзәтүләр Тукайда аналитик жанрлардан рецензияләрнең, әдәби күзәтүләрнең, проблемалы һәм теоретик характердагы мәкаләләрнең аз булуын күрсәтә. Югарыда М.Гафуриның “Хәмитнең хәяты яхуд Ләйлә вә хәятым” әсәренә язылган “Яңа әсәрләр (“Хәмитнең хәяты”)” (1911) рецензиясе, “Тәнкыйть – кирәкле шәйдер” (1907), “Галиәсгар әфәнде Камалның унъеллык юбилейсы” (1910) дигән юбилей мәкаләсе турында сүз алып барылды һәм шулай ук аларга Г. Тукайның тәнкыйди эшчәнлеген өйрәнгән И. Нуруллин [9], М. Гайнуллин [1], М. Мәһдиев [6], Р. Мөхәммәдиев [7] һ.б. ларның хезмәтләрендә әтрафлы, тирән бәя бирелгән.

Алда әйтелгәнчә, Тукай – иҗади шәхес, ул һәрвакыт эзләнүдә, яңалыкка омтылып яши. Рус әдәби тәнкыйтендә мөстәкыйль жанр буларак кабул

ителгән хат эпистоляр жанры да, Тукайлар – Ф. Әмирханнар чорында үзгәреш кичереп, әдәби берәмлекләрне бәяләү максатларында кулланыла башлый. Чыннан да, Тукай хатларында шәхси, автобиографик характердагы фактлар белән беррәттән, әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә, әдәби хәрәкәткә, яңа әсәргә, дөнья әдәбиятына бәя бирелә, мөнәсәбәт белдерелә, шагыйрь үзенең иҗат планнары белән дә уртаклаша. Аларда язучының аерым теоретик мәсьәләләр тирәсендә уйланулары да кызыклы, әдәбият тарихының, тәнкыйди фикернең галимнәр тарафыннан моңа кадәр игътибар ителмәгән яклары ачылып китә. Хатлар шул чор әдипләрнең иҗтимагый – әхлакый позициясе, эстетик идеал һәм зәвекъләрен тулырак күзалларга ярдәм итә.

Тукайның адресатлары киң һәм артык бай түгел, чөнки мәгълүм булганча, шагыйрь дуслар сайлауда аеруча таләпчән. Аның шәхси, иҗади дуслары Ф. Әмирхан, Г. Камаллар бу вакытта Казанда яши һәм иҗат итә. Шагыйрьнең хатларын актарганда, аларның күпчелегенең С. Сүнчәләйгә, Ә. Урманчиевка, кайберләрнең аерылышып торган вакытта Ф. Әмирханга юллануы ачыклана. Алар арасында К. Бәкер, Петербург имамы Сафа ахун Баязитов (“Нур” газетасы мөхәррире), Г. Шәрәф исемнәре бар. Г. Тукайның 4 томга урнаштырылган хатларның күпчелеге 1910-1911- нче елларга туры килә. С. Сүнчәләй бу вакытта, Р. Мусабекова күрсәтүенчә, Пермь губернасы Бардым өязе Сараш авылындагы дүртьеллык рус – татар мәктәбендә укытучы булып эшли. “Ялт –Йолт” сатирик журналы мөхәррире Ә. Урманчиевка адресланган Тукай хатлары шагыйрь Казаннан чит төбәкләргә сәяхәт кылганда язылганнар.

Г. Тукайның, Ф. Әмирханга, С. Сүнчәләйгә, Ә. Урманчиевка язган хатлары әдәби тәнкыйть билгеләрен гәүдәләндерә. Шагыйрь хатларында да принципиаль, шәхси мөнәсәбәтләрдән өстен, тугры сүзле, вакыты белән усал булып кала. Г. Тукай язмалары шулай ук заман әдәбиятының күп мәсьәләләрен күтәрүе, яңа әсәрләргә тәнкыйди фикерләре белән аерылып тора.

Тукай шигырь теориясенә, күләмле хезмәт язу теләге белән яшәсә дә, махсус гыйльми мәкалә, рисалә багышламый, әмма бу мәсьәлә тирәсендә аның гыйльми-нәзари күзаллаулары шагыйрьнең барлык тәнкыйди язмаларында, хатларында кызыл җеп булып сузылып бара. Мисалга ул шигырь төзелеше турында С.Рәмиев фикерләренә мөнәсәбәт белдереп, шигырьнең мәгънәви ягын һәм образлылыгын беренче планга чыгара: "Сәгыйть Рәмиевнең вәзеннәр тугрысында артык лаф сугуына исегез китмәсен. Әле без татарларда теория словесности вә шигырьләр өчен хорей, дактиль-фәләннәр ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк. Фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифәдә кирәк". <...>. Мин анда Нәҗип Думавиның "Сугыш", Бәширинең "Балалар теләге" исемендәге шигырьләрен, үзенә һич тә әһәмият бирмичә, фәкать мәгънәви яклары яхшы булганга күрә генә алдым" ("Сәгыйть Сүнчәләйгә. 1911 ел, 1 январь. Казаннан").

Әдипнең күп хатларында үзенең якын дусты С.Сүнчәләй шигырьләренә бәя бирелә, фикер сөрешендә иҗат лабораториясе, язучылык һөнәре мәсьәләләре тирәсендә уйланулары чагыла. Шагыйрь тәнкыйтьнең вазифасын киң аңлап, әсәрнең уңай яклары белән бергә кимчелекләрне дә күрсәтеп, язучыга ярдәм итү бурычын алга чыгара: "Кулыма төшкәндә шигырьләрегезне укыйм. Шөбһә юк, Сездә милләткә яки шөһрәткә бик кызу мәхәббәт бар. Әмма һәр язганыгызны нәфис вә изящный дип әйтсәм, мин, Сезгә дуст булудан бигрәк монафикъ (икейөзле, хыянәтчел) булудан куркам". Шагыйрь әсәрләрнең тел-стиль мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Аны әсәр матурлыгының бер шарты итеп карый. С.Сүнчәләй лирикасының телендә әдәби телне бозу очраклары күзәтелүен билгеләп, шагыйрьне алардан котылырга чакыра: "Аннан соң Сезнең шигырьләрегездә мин провинциальный һәм төп халык телендә булмаган сүзләр табам. Аларны катыштырмасагыз икән...” (1910 ел, 9 ноябрь. Казаннан).

Билгеле булганча, Г.Тукай замандашлары арасында оста тәрҗемәче буларак таныла һәм бәяләнә. Ул хатларында тәрҗемә әсәрләргә дә бәя бирә һәм, әйтергә кирәк, аның тәрҗемәчелек эшенә таләпләре югары. Ул С.Сүнчәләйнең «Шильон мәхбүсе»н тәрҗемә итәргә алынуына үзенең ризасызлыгын сиздерә: « «Шильон мәхбүсе»нә, минемчә, иртәрәк, көчегезнең микъдарын үлчәмичәрәк тотынганга охшыйсыз. Әүвәлдә 4-5 сәтырлык (юллык—Г.Т.) шигырьләрне асыл шагыйреннән калышмаслык дәрәҗәдә, гүзәл вә нәфис чыгарырга тырышырга кирәк иде. Менә Сәгыйть Рәмиев Пушкин "Пәйгамбәр"ен, мин фәкыйрь дә Лермонтов "Пәйгамбәр"ен тәрҗемә иттек. Безнең икебезнеке дә шактый шома чыктылар. Шулай да без әле олугъ поэмаларга тотынырга батырчылык итә алмыйбыз” (Сәгыйть Сүнчәләйгә, 1910 ел, 9 ноябрь).

Г.Тукай "Казан матбугатына айнык караштан аерылмау"ны төп таләп, тәнкыйтьнең төп шартларыннан берсе рәвешендә алып, үзе сәфәрдә вакытта 1912 нче елның апрель-май айларында басылган газета-журнал номерларына, аерым китапларга күзәтү ясый. Татар идеологы, дини реформаторы Муса Бигиевнең Коръән Кәримнең тәрҗемәсенә мөнәсәбәт уңаеннан Г.Тукай Ә.Урманчиевка юллаган бер хатында (1912 ел, 11 май. Уфадан Казанга) мәгърифәтче әдип Р.Фәхреддиннең әсәрләренә, ал арның тел-стиленә югары бәя бирә. Р. Фәхреддиннең “Әсма”, “Сәлимә” әсәрләрен тел, стиле, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары күтәрә: “Чөнки ул (ягъни Р. Фәхреддин – Г.Т.) “Әсма”, “Сәлимә” кебек китаплары белән язу көчен вә шигъриясен күрсәткән вә сөйләп аңлатып бирүе ачык, стиле җиңел вә гүзәл бер язучыдыр”. Г. Тукайның аерым хатлары күзәтү мәкаләсе жанрында да язылa.

Г.Тукай 1911 елның 4 мартында Сәгыйть Сүнчәләйгә язылган хатында Г.Ибраһимовның 1910-1911 елларда дөнья күргән хикәяләренә үз карашын белдереп уза. Әдипнең романтик әсәрләрендәге хикәяләүченең, яисә төп каһарманның фәлсәфи уйлануларын, хис-кичерешләрен киңәеп тасвирлаган өлешләрен кимчелек итеп күрсәтә: "Габди Галимҗанның вакытлы

матбугатта чыккан язулары шома, ихласлы вә шактый гына төпле чыгалар. Ләкин мин аның аерым рисаләләрендә күңелдә бер-бер төрле эз калдырырлык нәфасәт (нәфислек) вә мәһарәт (осталык) күрмим. 10 сәхифә дә язылырлык бер мәүзугка һәрвакыт әллә ничәшәр өлеш артык кәгазь исраф итә". Аның аерым хатлары тәнкыйди хәбәрләр белән дә баетылган. Алар гадәттә шагыйрьнең тәмамланган яисә басылып чыккан әсәрләре турында кыскача белешмә бирәләр: "Мин бу арада балалар өчен "Песи Г.Җамал" яки "Песибикә" (шагыйрьнең бу әсәре "Мияубикә" исеме белән басылып чыга - Г.Т.) исемле бер рәсемле рисалә язып бетердем. Шактый муаффәкыятьле чыкты; басылып чыккач, сиңа җибәрермен. "Күңел җимешләре" ике-өч көннән чыкса кирәк. Басыла башлады. "Халык моңнары"ның икенче җөзьенә (кисәгенә) бик изящный (гүзәл) материаллар таптым. Аны стряпать итеп (тиз генә эшләп) алырга торам". (Сәгыйть Сүнчәләйгә. 1911 ел, 4 март. Казаннан).

Тукай тәнкыйтьченең әхлакый позициясенә, эстетик зәвегы мәсьәләләренә кагыла, шулай ук үзенең иҗади бурычлары, планнары белән дә уртаклаша: "Бер поэма хакында башымда әнвагъ төрле (күп төрле) хыяллар йөри. Фәкать зиһен варить итеп (акыл пешереп) чыгарганы юк әле. Гаяи хыялым (хыялмның нәтиҗәсе) - татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер "Евгений Онегин" чыгарудыр". Кызганыч, шагыйрь әлеге изге хыялын тормышка ашыра алмый.

Тукай тәнкыйтьтә туры сүзлелекне, дөреслекне, гаделлекне яклый. Ул үз карашларын укучыларга җиткерү, әдәби күренешләр турында иҗтимагый фикер тудыру, үз позициясен яклау максатыннан, информатив хәбәр – мәкалә, аннотация, монолог һәм диалог шәкелендәге язмаларга, һәм үзендә шәрех белән фәнни бәхәсләрнең билгеләрен җыйган синтетик характердагы жанрара формаларга мөрәҗәгать итә. Билгеле булганча, Г.Тукайның 1911 елда “Живописное обозрение” журналындагы әсәргә ияреп эшләнгән “Мияубикә” әсәре “Йолдыз”газетасының 21 июне санында басылып чыга һәм жанры, төзелеше буенча әдәби бәхескә сәбәпче була. Аерым алганда, шушы уңайдан ике язма пәйда була. Г. Ибраһимов “Мияубикә” рецензиясендә әсәрнең жанрына шөбһә белдереп, аны “нәзым вә мәнзумә генә” [5. 54 б.] дип атый. Гарәп – фарсы метрик шигыре гаруз турында Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтулладан сабак алган, төрки – татар силлабик шигырен үзләштергән, рус поэзиясендәге силлабо – тоник, тоник шигырь системаларыннан таныш, хәбәрдар булган Тукай ,билгеле, әлеге рецензияне җавапсыз калдырмый. Ул мәкалә авторы белән фәнни бәхәскә кереп, бу әсәрен “саф поэзия, чын шигырь” [11. 128 б.] дип язып чыга.

Шунысы да мәгълүм: киңкырлы талант иясе, сәләтле Тукай зур иҗат планнары белән яши 1910 елларда мәктәп – мәдрәсәләрдә татар әдәбиятын предмет буларак укыту көн тәртибенә куелгач, милли зыялыларның бер өлеше әлеге юнәлештә эшчәнлекләрен активлаштырып җибәрәләр һәм аны үстерүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Аларның бер төркеме әдәбият теориясенең аерым өлкәләре өстендә эшләнгәннәр. Мәсәлән, Г. Тукай

Сәгыйт Сүнчәләйгә 1911 елның 4 мартында язган хатында болай дип искәртә: “Фатих Әмирхан күптәннән бирле теория словесности язып маташа. Мин дә аңа шул эштә азрак файдалы булмакчы булам. Шулай итеп, икәүләп, бәлки шигырь вәзеннәре хакында бер кагыйдә вә тәртип чыгармабызмы дип торабыз” [11. 101-102 б.]. Тукайга бу теләген тормышка ашырырга насыйп булмаса да, шигырь төзелеше хакындагы аерым гыйльми күзаллауларын матбугат битләрендә яктыртырга җай чыга. Алда әйтелгәнчә С. Сүнчәләй “Шура” журналының 1911 елгы 15 сентябрь (18 нче) санында “Сәгъде Вәкъкас” тәхәллүсе белән Тукайның “Мияубикә” сенә рецензия яза. Автор рецензиясенең башлам өлешен шигърият, шигырь – шагыйрь мәсьәләләре турында сүз йөртүдән башлый аңа рус әдәбиятыннан дәлилләр, мисаллар китерә дә, “Мияубикә”нең шигырь жанры таләпләренә җавап бирүен исбатлый: “Мияубикә” камил мәһарәт белән, шагыйранә һәм татарча ачык язылган” [9. 230 б.].

С. Сүнчәләй шигырьнең кимчелекләре төсендә рифманың аксавын күрсәтә: “Мияубикә”нең җитешмәгән урыннары булса, сәҗегъ – рифмаларының (актык сүзләрнең) ямьле оеша алмаулары өстән – өстәнлектер. Мәсәлән: нәрсәсен – нәрсәчөн, кәгазь – эшләмәс, нәрсәгә – мәсьәлә, куркалар – фәркы бар, тиз әнкәмә – зинһар тимә һәм башкалар” (9. 231 б.). Г. Тукай бу язмага “Сәгъде Вәкъкас әфәндегә” фельетоны белән “Ялт – йолт” журналының 1911 елгы 28 нче (12 октябрь) санында “Гөмберррт”имзасы астында җавап бирә. Язмада тәнкыйтьче шигырь теориясе, төзелеше, форма һәм эчтәлек категорияләренә нисбәтле нәзари карашлары белән уртаклаша. Ирония катыш юмористик стильдәге фельетонында мәкалә авторы XX гасыр башында шигъри форма хакындагы фәннең ритм, вәзен, рифма төшенчәләрен аңлауга үзеннән яңалык алып килә. Чыннан да , әле бу вакытта әдәбият теориясенең мөһим тармагы эшләнмәгән. Бу хакта Тукай үзе искәртүне кирәк дип таба: “Әле моңар кадәр бездә бертөрле һәркемне икънаг итәрлек (канәгатьләндерерлек) вә тәхриратны (иҗат ителгән әсәрләр) бер нәүгы (төрле) кагыйдә астына җыярдай "кавагыйде лисан” – “теория словестности” – мәйданга килмәгән булса да, мин “нәрсәгә” белән “мәсьәлә”нең вәзен булырга яраганлыгын дәгъва итәмен” [11. 151 б.]. Тукай оппоненты С. Сүнчәләй белән фәнни бәхәскә кереп, шигырьдә төгәл рифма түгел, ә төгәл булмаган рифмалар да яшәвен яклый. Үз карашын рус, төрек, гарәп, татар шагыйрьләре иҗатыннан кушма һәм гади рифма; ачык һәм ябык рифма, омонимик рифма; янәшә, аралаш, юаралаш рифмаларга мисаллар китереп, гомумән шигырь теориясе хакында татар нәзари фикеренең офыкларын киңәйтеп җибәрә.

Г. Тукай әдәби иҗатында татар тормышындагы искелекне, артталыкны, җитешсезлекләрне кире кагуда, фаш итүдә сатираны, аның алымнарын корал итүнең иң көчле үрнәген күрсәтә. Тәнкыйтьче заман әдәбиятындагы кимчелекләргә, сюжет – композициядәге ясалмалылыкка, идея – эчтәлектәге сайлыкка, форма белән берьяклы мавыгуларга кире мөнәсәбәтен белдерү максатыннан да , җитди фикер әйтү өчен дә сатира,

ирония, юмор мөмкинлекләрен киң файдалана. Язучы тәнкыйди эшчәнлегенең бу сыйфаты әдәби-публицистик төр, аның пародия, памфлет, фельетон, сатирик диалог кебек сатирик һәм юмористик характердагы жанрларны отышлы һәм максатчан куллануда күренә. Менә бу үзенчәлек Тукайны башка әдип – тәнкыйтьчеләрдән, профессиональ тәнкыйтьчеләрдән аерып куя һәм аның стиленең индивидуальлеген билгели. Автор аларда үткен, образлы тел белән әдәби әсәрләргә, әдәби барышка бәя бирә. Дөрес, хәзерге заман, иҗтимагый – милли хәрәкәт, гомумкешелек кыйммәтләр, тәнкыйтьченең һөнәри әхлагы ноктасыннан караганда, Тукайның аерым әдипләргә, шәхесләргә, зыялыларга, аерым әдәби әсәрләргә бирелгән бәяләре, әйтелгән сатирик репликалары белән килешмәскә дә мөмкин. Аны корректсызлыкта, фәннилектән китеп дорфалыкта, кайбер авторларның шәхесен кимсетүдә дә гаепләргә мөмкин. Бу җитешсезлекләр Тукай тәнкыйтенең оперативлыгы, аның характер сыйфаты, тугрылыгы, милли чынбарлыкны тиз арада мәдәниләштерү, яңарту омтылышы белән бәйле булса кирәк, ягъни аларның объектив һәм субъектив сәбәпләре бар.

Сатирик характердагы мәкаләләр үзенчәлекле композицияләре, фактлар байлыгы, үзара бәйләнмәгән иронияле, вакыты белән ачы, сарказмлы репликалар, диалогларның муллыгы кебек сыйфатламалары белән башка тәнкыйди жанрлардан аерылып торалар.

Тәнкыйтьченең мондый рухтагы язмаларында Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, М. Гафури, Г. Камал кебек күренекле татар әдипләре, З. Бәшири, Ш. Саттаров, Әхмәтҗан Биктимиров, Галиәсгар Гафуров – Чыгтай, Ф. Агиев кебек икенче дәрәҗәдәге шагыйрь, язучылар иҗатына һ.б. бик күп төрле татар зыялылары, шәхесләрнең эшчәнлегенә, эш гамәләләренә бәя бирелә: “Акыллы башлар” (1910), “Фәлсәфи сүзләр” (1910), “Әстерхан мөзакәрәләре” (1911) һ.б.

Әдәби – публицистик төрләрдән очерклар, аның бер төре – сәяхәтнамә – юлъязмаларны да Тукай тәнкыйди максатларда файдалана. Билгеле булганча, шагыйрь 1912 елның апрелендә татар зыялылары чакыруы буенча Уфа аша Петербургка сәяхәт кыла. “Ялт – йолт” журналы редакторы Әхмәт Урманчиев киңәше белән юл, сәяхәт вакытында күргән – белгәннәрен, тормышында булган вакыйгаларны, кызыклы шәхесләр белән очрашуларын, күңелендә туйган уй – фикерләрен кәгазьгә төшереп, “Мәкаләи махсуса” исеме астында укучы хөкеменә тәкъдим итә. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Исхакыйның иҗатларына, кайбер әдәби әсәрләренәт мөнәсәбәт белдерелеп узылган “Казанга кайтыш” (1912) язмасын да шулар җөмләсенә кертеп карарга мөмкин.

С. Рәмиев – Г. Тукайның әдәби һәм шәхси дусларыннан берсе. Араларында аңлашымаучылык аркасында, салкынаюлар булып алса да, аларның чын дуслыгы шагыйрьнең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Тукай, шагыйрь С. Рәмиевнең кайбер әсәрләренә көлкеле ияреп, шигырьләренең темасын, идея эчтәлеген пародия объектына әйләндерә. Мәсәлән, Тукай С. Рәмиевнең “Уку” (1907) әсәренә “Йокы” (1908), “Алданган” (1908)

шигыренә “Саташкан” (1908) пародиясен яза һәм шуның белән бу алымның тәнкыйди максатларда кулланыла алу мөмкинлеген күрсәтә.

Г. Тукай милли әдәбиятта шәркый традицияләр белән рус, гареб әдәбиятларының идея – эстетик кыймәтләрен, казанышларын синтезлауның, үреп үстерүнең иң отышлы үрнәкләрен күрсәтүчеләрнең берсе булды. Ул, ике мәдәният, ике дөнья шагыйрьләре иҗатыннан әдәби осталыкка өйрәнеп калмыйча, аларның иҗат дөньясына, рухи мирасларының идея – эстетик үзенчәлекләренә тәнкыйди карашларын да белдерә.

С. Сүнчәләй тарафыннан Байронның “Шильон мәхбүсе” исемле поэмасы тәрҗемә ителә. Аны укып чыкканнан соң, Тукайның “Мөкаддимә” исеме белән эчке рецензиясе языла һәм С. Сүнчәләйнең 1911 елда дөнья күргән китабына сүз башы итеп урнаштырыла. Тукай анда тирән фикерле, теоретик әзерлекле, әдәби зәвекъле тәнкыйтьче буларак чыгыш ясый. Инглиз шагыйре Дж. Байрон иҗатының асыл сыйфатларыннан берсе булган гыйсъянчылыкны, аерып чыгара, аннан соң әдәби – мәдәни бәйләнешләр мәсьәләсенә күчеп, Байрон шигъриятенең А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтовның дөньяга карашларына, каләмнәренә тәэсире турында сөйли: “Лорд Байрон әсәрендә мәгънәләр үз милләте вә үз мәмләкәте чигеннән үтеп, бөтен көррәй арызның (җир шары) хәссас (сизгер) вә көчле күңелләрен сил ташуы кебек басмыш вә тутырмыштыр. Мәсәлән, дөнья сараена әллә ничә гасырлар мөддәтендә (буенча) бер генә кат тәшриф итеп (аяк басу), анда да күп торасы килмичә, галәме мәләкүткә (мәңгелек дөньясы) сәфәр иткән Пушкинның яртыдан артык гомере мәзкүр (искә алынган) Байрон җәнабләренә тәкълид (иярү) вә аның рухыннан илһам эстәү белән үтмештер” [11. 126 б.].

Г. Тукайның аерым язмаларының жанрларын билгеләү шактый авыр. Мәсәлән, аналитик һәм әдәби-публицистик тәнкыйди жанрларның билгеләрен үзенә җыйган “Былтырның хисабы” (1912), “1912 нче елның онытылганнан калган гына хисабы” (1913), “Матбугатыбызның “фәсахәт нәмүнәләре” (1913) язмалары шундыйлардан. Автор аларда шушы елның әдәби хәрәкәтенә, матбугатына йомгак ясый, үзенең яңалыгы, идея эчтәлеге белән аерылып торган әдәби әсәрләргә катнаш стиль белән мөнәсәбәтен белдерә. Кыскача, үтемле тел белән укучыга китапның яңалыгын, уңай ягын, яки көйдереп ала торган ачы сарказм, нечкә ирония, җиңелчә юмор белән җитешсезлеген, кимчелеген күрсәтә. Г. Тукай “Былтырның хисабы” (1912) язмасында, Г. Камалның “Безнең шәһәрнең серләре” комедиясен татар тормышын, милли-мәдәни тирәлекне дөрес һәм образлы гәүдәләндерү ягыннан аерып куя һәм аның белән үзенең соклануын белдерә.

Соңгы еллар әдәбият белемендә некролог – тәгъзияләрне, аларның төрле формаларын әдәби тәнкыйть жанрлары эчендә карыйлар. Бу жанрларның үрнәкләре Тукайда да табыла. Мәшһүр рус әдибе Л.Н. Толстой вафаты мөнәсәбәте белән язылган “Мөбарәк тәсбих өзелде” (1910) некролог – тәгъзиясендә автор тарафыннан әдипнең рус һәм дөнья әдәбиятындагы бөеклегенә, әдәби мирасының байлыгына, рухи – мәдәни кыйммәтенә

импрессионистларча мөнәсәбәт белдерелә, әдип иҗаты һәм шәхесе югары бәяләнә.

Күренә ки, XX гасыр башында мөстәкыйль үсеш юлына чыккан әдәби тәнкыйть барлыкка килүне һәм формалашуны Г. Тукайның тәнкыйди эшчәнлегеннән башка тулы күзаллау да, объектив яктыртуда да мөмкин түгел. Тәнкыйтьче үзенең әдәби барышны бәяләгән язмалары белән дә, теоретик мәсьәләләргә кагылышлы мәкаләләре белән дә бу тармакның үсешенә җирлек әзерли, оператив һәм реалистик әдәби тәнкыйть теориясенең нигезен сала. Әдәби категория буларак, әдәби тәнкыйть жанрларының сыйфатлары Г. Тукай эшчәнлегендә ачыклана һәм әдипнең бу төр эшчәнлегендә чын мәгънәсендә үсеш, камилләшү кичерә.

**Әдәбият:**


1. Гайнуллин М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX века / М.Х. Гайнуллин. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1966. – 434 с.
2. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.
3. Гыйлаҗев Т.Ш. Г. Исхакыйның гыйльми – тәнкыйди эшчәнлегендә әдәбият мәсьәләләре / Т.Ш. Гыйлаҗев // Гаяз Исхакыйның тууына 130ел тулуга багышланган халыкара фәнни – гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008). – Казан, 2008. – 376 б. (101-108 б.)
4. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары) / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 271 б.
5. Ибраһимов Г. Мияубикә / Г. Ибраһимов // Г. Ибраһимов. Әсәрләр Сигез томда. 5 т. / Әдәбият һәм сәнгать турында мәкальләр, хезмәтләр (1910-1933) / Г. Ибраһимов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 54-56 б.
6. Мәһдиев М.С. Реализмга таба: XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре / М.С. Мәһдиев. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 1989. – 156 б.
7. Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1905-1917) / Р.С. Мухамадиев. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1982. – 144 с.
8. Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты / И.З. Нуруллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – 288 б.
9. Нуруллин И.З. Тукай эстетикасы турында мәкаләләр / И.З. Нуруллин // Казан: Таткнигоиздат. - 1956. – 135 б.
10. Сүнчәләй С. Мияубикә // Сүнчәләй // Сүнчәләй С. Әсәрләр һәм хатлар / Төзүчесе З. Рәмиев / С. Сүнчәләй. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 367. (230-231 б.)

11. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 т. / Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 383 б.
12. Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 т. / Мәкаләләр. Очерклар. Фельетоннар. Хатлар (1902-1913). / Г. Тукай. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. – 431 б.
13. Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 т./Мәкаләләр. Хикәяләр.Мәсәлләр.- Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. – 447 б.